СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Ташкичү авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**“08”ноябрь 2019 ел** **№41**

**Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 декабрендәге 24 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (16.04.2019 ел, №26 үзгәрешләр белән)**

“Мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында” һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон тарафыннан Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 65 статьясына үзгәрешләр кертелү сәбәпле, Ташкичү авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1. Ташкичү авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 декабрендәге 24 номерлы карары белән расланган (16.04.2019 ел, №26 үзгәрешләр белән) Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Нигезләмәнең 15.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6) шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, шул исәптән электрон документ формасында;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтына (http:arsk.tatarstan.ru) һәм Ташкичү авылы, Ленин урамы, 53 нче йорт; Ашытбаш авылы, Г.Тукай урамы, 19 нчы йорт; Иске Ашыт авылы, Мәктәп урамы, 4 нче йорт адреслары буенча халык күпләп җыела торган урыннардагы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны өстемдә калдырам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.Фәйзуллин

СОВЕТ ТАШКИЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ